**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

____________ № _____

«2023 елда Актаныш муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру турында» 2022 елның 23 декабрендәге ПР-274 номерлы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2023 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, «2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карарын (11.10.2021 елның 968 номерлы карары үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2022 елның 05 сентябрендәге 961 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитет җитәкчесенең «2023 елда Актаныш муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру турында» 2022 елның 23 декабрендәге пр-274 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2011 елның 12 апрелендәге 302н номерлы боерыгы таләпләренә ярашлы рәвештә, 3 пунктның өченче абзацындагы, «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрының «Мәҗбүри рәвештә алдан һәм даими медицина тикшерүләре үткәрелә торган зарарлы һәм куркыныч җитештерү факторлары һәм эшләр исемлеген һәм зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартлары булган авыр эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә мәҗбүри алдан һәм даими рәвештә тикшерүләр уздыру тәртибен раслау турында» түбәндәге җөмләне төшереп калдырырга.

1.2. 1 нче кушымтаның 4 пунктын «2023 елга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ял итү программасы» «Көндезге лагерьда (мәктәп яны) сменаларны оештыру»ны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Үткәрү территориясе | Кеше саны* | Көн саны * | Юлламаның норматив бәясе | Бюджеттан субсидияләр* | Ата-аналар взносы* | Башка чаралар (предприятиеләр, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда | | | | | | | |
| Актаныш районы белем бирү | Актаныш районы | 265 | 21 | 4950,00 | 4207,00 | 743,00 | 42,00 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оешмалары базасы | | | | | | | |
| Калган чорда (көз, кыш) | | | | | | | |
| Актаныш районы белем бирү учреждение ләре базасы | Актаныш районы | 490 | 7 | 1650,00 | 1402,00 | 248,00 | 14,00 |

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче Р.А. Ильясов